## *Газизов Самат*



*Мин, Газизов Самат 1942 нче елда туганмын. Сугыш беткәндә миңа 3 яшь иде. Әни сөйләгән буенча, сугыш вакытында бик авыр булган. Әни колхозда эшләде, ә әти сугыш башлангач, сугышка китте, аннан яраланып кайтты. Без кузгалак, күкәрин, акбаш, кычыткан ашап үстек. Мин 7 класс укыдым. Миңа 12 яшь тулгач, әти үлеп китте. Без, 3 баланы әни тәрбияләп үстерде. Хәзерге балаларга укырга да, яшәргә дә тормыш шартлары бик килгән. Кадерен белеп, тырышып укысыннар. Илләребез тыныч булсын.*